وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№8 (125). 24 февраль 2012 / 2-раббигыль-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



*"Рубин" капкачысы:* "Казанда хәләл ризык куллана алуыма шатмын"

▷2◁



Борынгы болгарларда тарихи-мәдәни эшчәнлек

▷3◁



Кытайда Коръән музее төзеләчәк

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ: АЛАБУГА РАЙОНЫ**

ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Коръән елы уңаеннан Коръән укучылар бәйгесенең район этабы башланып китте. Беренче этапта республиканың барлык районнарын колачлаячак әлеге бәйгене беренчеләрдән булып 19 февральдә Алабуга районы мөхтәсибәте үткәрде.

Конкурста унҗиде кеше катнашты. Алар өч яшь категориясенә бүленеп ярышты:

- 5 яшькәчә балалар;
- 5-10 яшьлек балалар;
- 10-15 яшьлек балалар.

Нәтиҗәдә, тугыз катнашучы җиңүче дип табылды. Бәйге иң осталарны бүләкләү белән тәмамланды. Соңыннан, барлык катнашучылар да чәй табынында очрашты, аларга вәгазь сөйләнде.

**"БИЛӘР" КАФЕСЫНДА – ХӘЙРИЯ АШЫ**

21 февраль көнне "Зәкят" хәйрия фонды тарафыннан мохтаҗлар өчен "Биләр" кафесында хәйрия ашы үткәрелде. Әлеге чарага ялгыз яшәүче өлкәннәр, сукырлар, аз керемле гаиләләр, ятимнәр, күп балалы аналар килгән иде. Кунаклар каршында сәламләү сүзе белән "Зәкят" хәйрия фондының генераль директоры Рөстәм хәзрәт Ясәвиев чыгыш ясады. Чарада катнашучыларга татар милли ашлары тәкъдим ителде. Очрашу дустанә һәм җылы аралашуга әверелде.

"Зәкят" хәйрия фонды катнашучылар исеменнән "Биләр" кафесының генераль директоры Булат Роберт улы Нагаевка һәм чараны оештырырга ярдәм иткән барлык хезмәткәрләргә дә рәхмәтебезне җиткерәбез. Барлык кылган изгелекләрегез кабуллардан булса иде!

**ЧЕЧНЯ ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШУ**

22 февральдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Чечня Республикасы мөфтие урынбасарлары Хәмзәт Шамил улы Дурдиев һәм Мөхәммәд Гариф Габдессәламов белән очрашты. Очрашу вакытында мөселман өммәтендәге вәзгыять турында фикер алышынды, Татарстан һәм Чечня дини оешмалары арасындагы хезмәттәшлек турында килешенде.

Очрашуда шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында эшләүче "Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Динар Садыйков та катнашты.

**МӨСЕЛМАН ЭШМӘКӘРЛӘРЕ АССОЦИАЦИЯСЕ КИҢӘШМӘ УЗДЫРА**

24 февраль көнне Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе хаҗи костюмының моделен ясау буенча конкурс оештыру һәм аны үткәрү мәсьәләләре буенча фикер алышырга ниятли. Чарада катнашырга теләгән дизайнер һәм модельерларны мөфтият бинасында (Лобачевский урамы, 6) көтеп калабыз. Башлана - 18.00 сәгатьтә. Киңәшмәдә ассоциация әгъзалары, Мәккә һәм Мәдинә җирләренә хаҗ сәфәрен оештыру белән шөгыльләнүче туристик оператор вәкилләре дә катнашыр дип көтелә.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Исламда социаль сәясәт

**РФ Премьер-министры һәм илебез президентлыгына кандидат Владимир Путин үзенең чираттагы мәкаләсендә җәмгыять тормышының иң мөһим өлкәләренең берсе - иҗтимагый сәясәткә кагыла. Ислам динендә иҗтимагый өлкәгә бик зур игътибар бирелә. Социаль яктан иң зур яклауны ислам дине бирә дисәк, ялгыш булмас. Бу - Коръәни-Кәримдә язылган һәм пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) хәдисләрендә чагылыш тапкан.**

Бүгенге көндә җәмгыять аңында баручы үзгәрешләр беркемне дә гаҗәпкә калдырмый дияргә була. Өлкәннәргә карата ихтирамсызлык нормага керде: һәркөн диярлек без әнисен кыйнаган яисә куып чыгарганнар турында ишетеп торабыз. Рухсызлык, кансызлык аркасында җәмгыять таркала. Ничек кенә теләсәк тә, балалар һәм картлар йортлары бушамый. Туйганчы ашарга мөмкинлекләре булмаган кешеләр дә бар. XXI гасырда, биек йортлар, зиннәтле сарайлар төзелгәндә, урамда салкыннан үлүче кешеләр барлыгын ишетү куркыныч хәл бит.

Социаль яктан яклау булмаган кешеләргә ярдәм күрсәтү өчен ислам дине нәрсәләр тәкъдим итә соң? Барысын да рәттән карап үтик. Ислам динендә гаиләгә мөһим урын бирелә. Аналарның дәрәҗәсе бик тә югары. Йөкле чакта һәм бала тапкандагы авырлыкларны тиешенчә кабул итеп күтәрсә, Аллаһы Тәгалә аналарга савапларын бирә. "Җәннәт аналарның аяк астында", - диелә пәйгамбәребез (сгв) хәдисендә. Мөселман кешесе ата-анасына "уф" дип тә әйтергә тиеш түгел. Бүгенге көндә аналарны һәм балаларны яклауга юнәлтелгән сәясәт һичшиксез дәвам итәргә тиеш. Икенче балаларын табучыларга бирелә торган ана



капиталы, күп балалыларга биреләчәк җир - болар барысы да, әлбәттә, гаилә тормышын җиңеләйтүче матди факторлар. Җитлеккән гаилә институтлары булу - җәмгыятьнең дөрес үсешен күрсәтә.

Картларга карата ихтирамга килгәндә, хәлләр авыррак. Кавказда картларга карата нинди ихтирам булуына игътибар итегез: туксан яшьтә дә, йөз яшьтә дә алар игътибар үзәгендә. Шуңа күрә алар картаюдан, җәмгыятьтә булган тетрәүләрдән, мохтаҗлыктан курыкмыйлар. Балалар һәрвакыт алар белән. Картларга карата хөрмәт мисалларын эзләп ерак барасы юк - татарларда әби-бабайларны һәрвакыт хөрмәтләп, ихтирам итеп яшәгәннәр. Авыру кеше булган элеккеге авыл йортларын искә төшерегез. Ул гаилә тормышының үзәгендә торган. Эшләргә, гаиләне тәэмин итәргә кирәк дип, беркем дә зарланмаган. Бүген балалар картайган ата-анасын карамас өчен мең төрле сәбәпләр уйлап таба. Бетерешкән картны кем үзенә алып карарга тиешлеген ачыклаганда, әрләшеп, журналистларны чакырып, аны тирә-юньгә таратып, мәсхәрә кылып бетерәләр. Уйланыгыз: картайган әти-әнисен караудан баш тарткан кеше үз теләге белән Аллаһы Тәгалә биргән бәрәкәттән баш тарта бит.

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

# СӨЙЛӘМЕҢ МАТУР БУЛСЫН!

**"(Ий, Мөхәммәд), син Раббың юлына хикмәтләр һәм матур үгетләр белән чакыр, алар белән бик тә гүзәл рәвештә бәхәсләш. Аллаһ тугры юлдан язганнарны бик яхшы белеп тора, Ул тугры юлга басканнарны да бик яхшы белә" ("Нәхел (Бал корты)" сүрәсенең 125 нче аяте).**

Без ни дәрәҗәдә дөрес һәм матур итеп сөйләшәбез, үз фикерләребезне үтемле итеп белдерәбез? Барыбызның да оста теллелеккә (красноречие), ораторлык сәнгатенә, аһәңле әдәби сөйләмгә, тукайча саф татар теленә ия булуыбыз да бик шикле әле. Ә моңа тиешенчә өйрәнергә кирәк, чөнки һәр көн безгә аралашырга туры килә: укуда булсын, эштә, хәтта үзебезнең өйдәгеләребез - гаилә әгъзалары белән дә. Балалар белән дөрес итеп сөйләшү, фикереңне ачык итеп белдерү - әгәр дә балаларыбызның яхшы тәрбия алуын телибез икән, монысы да бик мөһим эш. Хәзерге чорда урамда йөргәндә, еш кына бик кечкенә малайларның да, әхлак киртәләренә сыймаган лексика куллануын ишетеп колаклар "ояла". Алар, җитмәсә, сөйләмнәрендә барлык мөмкин булган жаргон, еш кына арго сүзләрне дә куллана бит әле!

Үз-үзеңә сорау бирәсең: шул дәрәҗәдә саекты микәнни соң бөек татар теле? Юк, әлбәттә, ничек булган булса, ул бөтен барлыгы белән матур һәм бай тел булып кала бирә, без аны үзебез шулкадәр ваклап бетердек ки, хәтта хисләребезне әлеге арго-жаргоннардан тыш белдерә дә алмый башладык. Эшләр шулай барса, бик тә кызганыч. Ә бит мәктәп программасында "Рус теле һәм сөйләм әдәбе" ("Татарский язык и культура речи" дигәне юк) дигән дәрес тә каралган. Исемдә: мин укыган чорда нәкъ менә шушы фән барлык сыйныфның да иң яраткан шөгыле иде. Безгә анда нинди генә биремнәр эшләргә туры килмәде: рәсемнәрнең сүзле текстын язу; бик тиз генә (экспромпт) мини-сочинение уйлап сөйләү; сулыш, тавыш күнегүләре үтәү... боларның һәммәсе дә сөйләмне генә түгел, фикерләүне дә үстерергә ярдәм итте.



## Ораторлык сәнгате: кичә һәм бүген

Әлбәттә, Борынгы Греция, Борынгы Рим матур, үтемле сөйләү (ораторлык) сәнгатенең ватаннары булып санала. Матур итеп сөйләү ул вакытта изге эш саналган. Ул әлеге әһәмиятен бүген дә югалтмады. Элеккеге чорларда чыгыш ясау өчен барлык текстлар да "сүз"гә, фикергә ия булган билгеле бер кешеләр тарафыннан язылган. Бу хәзер дә күзәтелә. Халык алдында оста чыгыш ясау барлык чорларда да үзенең мөһимлеген, мәгънәсен югалтмады. Табигый ки, җитәкчеләрнең, сәясәт эшлеклеләренең, укытучы-остазларның, мөгаллимнәрнең, суд залларында чыгыш ясаучыларның, адвокатларның сөйләмнәре элек-электән күрекле булган һәм ул шулай булып калачак та. Сүзләрнең дә мәгънәви йөге гасырлар дәвамында үз көчен югалтмады: сүз өчен хөкем дә иткәннәр, һәм ул ялкынлы, миһербанлык таләп иткән чыгыш кешеләрне үлемнән дә коткарып калды.

Ораторлык сәнгате - мәдәният үсешендә мөһим этап: кешеләр ни дәрәҗәдә төгәлрәк, мәгънәле сөйләшсәләр, алар үзләре дә шул дәрәҗәдә мәдәниятлерәк булып күренәчәк.

Үзен дәрәҗәле (зыялы) дип санаучы теләсә кайсы гаилә үз баласын укыту өчен сүз осталарына җибәргән. Морза гаиләләрендә әлеге дәрес мәҗбүри булган, аны, бернигә дә карамыйча, барысы да өйрәнгән. Ораторлык сәнгатенә, чит телләр белән бертигез дәрәҗәдә, малайлар һәм кызларны кече яшьтән үк өйрәткәннәр. Ул вакытта дөрес, итагатьле, барлык кешеләргә дә аңлаешлы телдә фикерен җиткерә алмаган кеше тәрбиясез булып саналган. Әлбәттә, безнең көннәрдә дә дөрес сөйләшә белүчеләрнең бәһасе, дәрәҗәсе гаять тә югары.

Оста сөйләм дәресләре, риторика фәне, төрле вакытларда барлык уку программаларына да кертелгән булган. Дини белем бирүдә бу искәрмә булмаган, әлеге предмет (гарәп телендә - хатыйблык) шулай ук мәҗбүри булган. "Хатыйб" дип вәгазьләүче, вәгазь сөйләүче, дини хөтбәләрне яки хөкем, сәясәт карарларын укучыны гына түгел, гомумән, оста-матур итеп сөйли белүчене дә атап йөрткәннәр. Мәдрәсәләрдә "Әдәбе рисаләт" (пәйгамбәрләр, илчеләр әдәбе), "Әлкифая" (рифма, көйләп уку) кебек китаплар файдаланылган. Билгеле, бу гыйлемнәр дини тәгълиматларны өйрәнү белән бергә үрелеп барганнар. Шуңа күрә яңа бер профессия - ораторлык сәнгатен үзләштергән һәм аны өйрәтүче дин галимнәре - имам-хатыйблар барлыкка килгән һәм үсеп киткән. Сөйләшә белү, сүз сәнгатенә ия булу иң мәртәбәле, иң кирәкле эш саналган.

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

# Иң сыйфатлы хәләл ризык кайда?




***Татарстанда III Халыкара KAZANHALAL-2012 күргәзмә-ярминкәсенә әзерлек эшләре дәвам итә. Быел әлеге чара тагын да масштаблырак һәм кызыклырак булырга ошаган, дип яза www.intertat.ru сайты.***

Күргәзмә 19-21 май көннәрендә KAZANSUMMIT-2012 ислам бизнесы һәм финансларының IV Халыкара саммиты кысаларында үткәреләчәк. Чарада катнашырга теләк белдерүчеләр арасында хәләл ризык җитештерүчеләр генә түгел, ә косметика, милли һәм мөселман киемнәре, әдәбият, сувенирлар сату белән шөгыльләнүчеләр, шулай ук туристик һәм медицина хезмәте күрсәтүче оешмалар да бар.

Чараның төп максаты - халыкны үзебездә һәм чит илләрдә җитештерелүче сыйфатлы хәләл ризык белән таныштыру. Халыкка әлеге продуктларның хәләл икәнен генә түгел, ә экологик таләпләргә туры килә торган, сәламәтлек өчен файдалы азык-төлек икәнлеген аңлату да төп бурычларның берсе. Тик шунысын да онытырга ярамый: хәләл дигәндә ашау продуктларын гына түгел, ә финанс, медицина, туристик хезмәтләрне дә күз уңында тотарга кирәк.

Тагын бер мөһим нәрсә: "KAZANHALAL"нең оештыру комитеты Малайзия, Һиндстан, Индонезия, Пакыстан, Төркия һәм БДБ илләре белән тыгыз элемтәдә тора. Шул рәвешле, бу чара Россиянең гарәп илләре белән хезмәттәшлеген ныгытуга зур өлеш кертә. Быел әлеге күргәзмә-ярминкәдә йөз иллегә якын компания-экспонент катнашыр дип көтелә.

***Рәмзия ЗАКИРОВА***

# Исламда социаль сәясәт

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

Соңыннан, ни өчен гаиләсен туйдыру өчен гомер буе көч түгеп эшләп тә, начар яшим дип, гаҗәпкә кала ул. Аллаһы Тәгалә биргән мөмкинчелекнең начар якларын гына күреп, аны кире кагуын уйламый.

Әлбәттә, барлык ятимнәрнең һәм картларның аларны карый алырлык туганнары юк. Ялгыз кешеләр дә бар. Ләкин ислам динендә аларның ялгызлыклары шартлыча гына. Динебез системасы бер-береңә булышлык күрсәтү, мәхәббәт белән карау, хәлсезләрне, җәберләнүчеләрне, кимсетелүчеләрне яклауга нигезләнгән. Аллаһы Тәгалә безне кемне дә булса кимсетүдән сакланырга чакыра. Ислам динендә социаль яктан яклаулары булмаганнарга булышлык күрсәтү өчен тулы бер система төзелгән. Беренчедән, бу - мәхәлләләр. Зур шәһәрләрдә берничә мәхәллә, ә авылларда берешәр булган алар. Әмма социаль тигезсезлек һаман да күзәтелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) вакытында байлар да, ярлылар да булган. Ләкин алар барысы да бертөрле яшәгән: ислам дине таралуга бертигез өлеш керткән. Байлар мәхәлләдәге мәчетләрне тәэмин итеп торган, эш урыннары булдырган. Урта хәлдәгеләр һәм ярлылар хезмәт иткәннәр һәм аның хакын алганнар. Нәтиҗәдә, бердәм тотрыклы икътисад барлыкка килгән.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең иҗтимагый сәясәте, беренче чиратта, атеизм елларында кулланылыштан төшеп калган ислам дине күрсәтмәләрен һәм гореф-гадәтләрен торгызып, мохтаҗ хәлдәге мөселманнарга ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән. Нәкъ менә шушы максатта "Зәкят" хәйрия фонды эшләп килә. Катлаулы операцияләргә акча җыю, картлар һәм балалар йортлары өчен уенчыклар, памперслар һәм башка кирәк-яраклар алу, Рамазан аенда ифтар мәҗлесләре үткәрү, зәкят җыю - болар барысы да мөселман өммәтенең үсешенә китерә. Бу эшләргә республикабызда яшәүчеләрнең кушылуы бик тә шатландыра. Башкаларга булышып, без зур саваплар алабыз, Иншә Аллаһ, Раббыбыз безгә бу әҗер-савапларның рәхмәтен Кыямәт көнендә күрергә насыйп итәр. Бизнеста уңышларга ирешкән мөселманнарның шәригать кануннары буенча эшләү өчен үз теләкләре белән берләшүе - бик күңелле күренеш. Аларның мөселман кардәшләренә булышырга әзер булулары куандыра.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# "Ят бала була алмый"

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) бер хәдисендә: "Изгелек кылуда ярышыгыз", - дип әйткән. Хәзерге вакытта изгелек кылучы кешеләр юк түгел, алар һәр матбугат чарасында диярлек яктыртылып тора. Бу күренеш, әлбәттә, безне куандыра. Әмма дә ләкин, як-ягыбызга карасак, безнең ярдәмгә мохтаҗ булучыларның саны шактый күп булып кала бирә.**

Шуны раслап, "Выбор" исемле оешма ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының мәдәният үзәгендә "Ят бала була алмый" исемле хәйрия концерты оештырды. Чарада танылып килүче җыр-бию коллективлары чыгыш ясады. Араларында - "Шәрык" клубында барлыкка килгән Axelle исемле рэп төркеме дә бар иде. Чара барышында җыелган акчалар әллә ни күп булмаса да, алар гарип балаларга коляскалар алырга тотылачак. Битараф булмаган яшьләр күбрәк булса, киләчәгебез тагын да яктырак булыр иде дип ышанып калабыз. Яхшылыклары үзләренә меңе белән әйләнеп кайтса иде.

**Ләйсән ГОБӘЙДУЛЛИНА,**
**КФУның журналистика һәм социология факультеты студенткасы**

# "Рубин" капкачысы:
## *"Казанда хәләл ризык куллана алуыма шатмын"*

***Иран "Персеполис"ыннан Казанга күчеп килгән "Рубин"ның яңа капкачысы Алирез Хагиги мөселманнар яшәгән республика командасы өчен чыгыш ясавына шат булуын җиткерде.***

Исегезгә төшерәбез: Хагиги быелның гыйнвар ае урталарында "Рубин" белән контракт төзегән иде. 23 яшьлек уенчы белән килешү дүрт елга исәпләнгән.

Хагиги Казанда җомга намазларына йөрергә исәпли. "Мин монда хәләл ризык куллана, мәчеткә җомга намазларына йөреп үземне уңай хис итә алачакмын", - дип сөйләде футболчы.

Ул шулай ук футболдан тыш мавыгулары турында да искәртте: "Буш вакытларымда кино карыйм, китаплар укыйм, гыйбадәт кылам. Мин әле Казанда озак булмадым, әмма шәһәр миңа бик тә ошады".



# СӨЙЛӘМЕҢ МАТУР БУЛСЫН!

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

Ораторлык-хатыйблык гыйлеменә өйрәткән хезмәтләр безнең халыкта күп булган булырга тиеш. Ләкин аларның мирасы хәзерге көнгә кадәр килеп җитә алмаган. Шулардан, мәсәлән, Болгар галиме Борһанетдин әл-Болгари "Әдәп шәрехе" һәм риторикага багышланган хезмәтләре белән мәгълүм. Р.Фәхреддиннең риторикага багышланган хезмәте булуы билгеле. Ләкин бүгенге көннәргә кадәр дә килеп җитеп, киң катлау укучыларга таныш булган хезмәт - ул Җиһангир бине Абызгильдинның "Хөтбәт ысуллары" исемле хезмәте.

Бүгенге көндә югары уку йортларында риторика мәҗбүри дәүләт стандартларына керә. Әлбәттә, бер семестр эчендә дөрес сөйләшергә берничек тә өйрәтеп бетереп булмый, моңа балачактан өйрәнергә кирәк. Әмма аның вуздагы программасы гына да (студентларның тырышлыгы нәтиҗәсендә) әлеге изге эштә кайбер белем һәм күнекмәләр бирә ала.

## Сүз белән кешене дәвалыйлар һәм гарипләндерәләр

Дөньякүләм атаклы актёр һәм режиссёр К.С.Станиславский: "Аралашканда сез, барыннан да бигрәк, кешенең күңеленә, аның эчке дөньясына тәэсир итәргә тырышасыз", - дип юкка гына искәртмәгән.

Әгәр дә сөйләшү тыңлаучыга тәэсир итәрлек тиешле "дулкын"ын таба алмаса, ул беркайчан да аның җанына һәм акылына йогынты ясый алмаячак. Аудиториянең кәефен дөрес тоемлап, тиешле нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Һәм, әлбәттә, бары тик йогынтылы, чын йөрәктән әйтелгән сүзләр генә сөйләмне истә кала торган һәм гамәлгә ашыра торган итә ала.

Әгәр дә сөйләм һәм һөнәрләр турында сүз башласак, дин әһелләре; табиб, психолог, укытучы кебек белгечләр, башка беркемнән дә ким булмаган дәрәҗәдә, матур сөйләмгә ия булырга тиешләр. Күз алдына гына китерегез, әгәр дә табиб авырулар белән тупас тонда, илтифатсыз рәвештә сөйләшсә, ахыры ни белән бетәр икән? Бар дәвалау чаралары, алымнары үзенең кире нәтиҗәсен бирәчәк. Тикмәгә генәдер инде сүз белән үтереп тә була дип әйтмиләр. Психологлар көн саен кешеләрнең четерекле мәсьәләләрен хәл итәләр. Алар урынлы сүз сайлау очраклары белән яхшы таныш. Психолог-табибның бурычы - кешеләрне күңел төшенкелеге халәтеннән чыгару. (Бу тормышта һәрбер шәхес белән проблемалар аз була димени?!) Риторикадан күнекмәләре булган психолог ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләргә булыша алачак.

Хәтта гадәти, һәрвакыттагы очракларда да уйлап әйтелгән сүз зур көчкә ия: озын-озак эш көненнән арып кайткан ир-атны яки мәктәп баласын дөрес итеп каршы алу дисеңме... (Ә бәлки улың яки кызың үз җавабыннан яки контроль эшеннән канәгать түгелдер һәм аларның кәефләре киткәндер!) Безнең белән нәрсәләр генә булмый, һәм дәшмичә дә калырга ярамый. Шул сәбәпле, ораторлык сәнгате безнең тормышыбызның аерылгысыз өлешен тәшкил итә, һәм, без теләсәк-теләмәсәк тә, аралашу өчен сөйләм кануннарын белергә тиешбез.

Татар халык мәкалендә болай диелә: "Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар". Безне җәмгыятьтә ничек кабул итүләре - күп очракта авызыбызны ничек ачуыбыздан, ничек сөйләшә башлавыбыздан тора. Тагын бер мәкаль бар: "Сүз чыпчык түгел, очып чыгып китсә, тота алмассың". Сүз гел югары бәяләнә һәм ораторлык сәнгатенә ия кешеләр дә зур хөрмәт белән файдаланалар. Димәк, безгә дә үзебезнең мәртәбәле остазларыбызның остазларыннан калышырга ярамый.

## Кешеләрне күркәм вәгазьләрең белән чакыр

Мин юкка гына иң әүвәл изге Коръәннән аять китермәдем. Мөселманнарга иң төп Китапта да дөрес һәм матур итеп сөйләшү йөкләнелә. Мөселман кешесе үзенең бурычларыннан тыш, башка кешеләрне дә тугры юлга өндәргә тиеш. Ягъни чакыру - дәгъват алып барырга. Әгәр дә без төрле телләрдә, төрле дәрәҗәләрдә аралашсак, безне ничек ишетерләр соң? Масса, халык алдына чыгар алдыннан, әңгәмә барышында сүзләр эзләп азапланмас өчен яхшылап әзерләнергә кирәк, - сүзләр тыңлаучыларга бер тоташ агым булып ирешергә тиеш.

Пәйгамәребез Мөхәммәдкә (сгв) сугышлар алып барырга туры килгән, әмма бу аның сугышасы килгәннән түгел иде, - моның сәбәпләре бөтенләй башкада булган. Аның төп коралы булып сүз торды, ул тулаем бер кабиләгә дә һәм аерым бер кешеләрнең һәрберсенә дә якын килү юлларын таба ала иде. Кайберәүләр аның сүзләренә колак салмады, әмма бу шулай ук аерым сөйләшү темасы. Аңа иярүчеләр күпкә күбрәк иде; алар Аллаһка һәм Аның илчесенә ягымлы сүзгә, акыллы сөйләмгә һәм матур нәсихәтләргә мөнәсәбәтле ышандылар. Пәйгамбәребез (сгв) беркайчан да кирәкмәгән сүзләргә, дискуссияләргә кереп китмәде. (Моны безгә дә эшләргә ярамый һәм аны гел истә тотарга кирәк.)

Бүгенге көндә дә көч белән бернәрсә дә исбатларга кирәкми, барысын да үтемле сөйләм аша эшләргә мөмкин, һәм бу зур уңышка китерәчәк.

Телдән сөйләм культурасы уникаль, безгә укуга яки карауга караганда, тыңлау күпкә җиңелрәк бирелә. Һәрбер сөйләм фикере үзенә ышандыра торган көчле дәлилләргә ия булырга тиеш. Шулай ук фикереңне нәтиҗәле исбатларга да туры килә. Шушы гади генә кагыйдәләрне үтәп, күп кенә теләкләргә ирешергә мөмкин.

Гегель болай дигән: "Сөйләм - гаҗәеп көчле чара, әмма аны куллану өчен бихисап күп акылга ия булу кирәк". Безнең бу дөньяга килүебез, мәгънәле һәм камил акылга ия булуыбызны раслау өчен дөрес һәм матур сөйләшергә өйрәнүебез таләп итәлә!

***Нияз САБИРҖАНОВ***



# БОРЫНГЫ БОЛГАРЛАРДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ ЭШЧӘНЛЕК

## 2012 ЕЛ – ТАТАРСТАНДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

Эшчәнлек – кешенең дөньяга мөнәсәбәтенең нигезе. Бу процесс барышында ул, кагыйдә буларак, матурлыкны танып белә. Шулай итеп, шәхес тормышта төрле эстетик кыйммәтләрне (матурлыкны, күркәм хисләрне, көлкеле күренешләрне, күңелсез, трагик вакыйга-хәлләрне) билгели башлый. Кешенең эстетик эшчәнлегe тормышның барлык якларында чагылыш таба.





Татарстанда эстетик тәрбиянең тарихын аңлау өчен моннан күп гасырлар элек үк бу төбәктә яшәгән халыкның рухи һәм художество эшчәнлегe үсешен өйрәнергә кирәк. Ул исә тарихи-мәдәни тормышның бердәмлеген аңларга ярдәм итә.

Шул уңайдан Болгар дәүләте халыклары мәдәнияте культурасын өйрәнү зур әһәмияткә ия, чөнки милләтебезнең рухи һәм матди тормышы байлыгын үзенә мирас итеп алган әлеге дәүләт татар халкының мәгарифе һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән.

Кызганыч ки, борынгы халыкның мәдәни байлыгы безнең чорга археологик казылмалар рәвешендә генә килеп җитте.

Идел Болгарстаны, дәүләт буларак, төрки телле кабиләләрнең берләшүе нәтиҗәсендә IX-X гасырларда барлыкка килә. Бу процесста болгар кабиләләре төп урынны алып тора. Шуңа күрә, ул Болгар дәүләте, ә аның халкы болгарлар дип атала башлый. Бу дәүләт башкаласы илнең икътисади, социаль-сәяси тормышында һәм, гомумән, ил тарихында мөһим роль уйнаган. Анда илнең төп байлыгы һәм халыкның икътисади, мәдәни казанышлары, шулай ук болгарларның киң сәүдә-икътисади, мәдәни-дини элемтәләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән байлык та тупланган.

Сәүдә итү болгарларның төп эшчәнлеге булган. Күренекле тарихчы М.Г.Худяков язганча, болгарларга сәүдә итә белү сәләте тумыштан ук бирелгән. Табигый ки, киң һәм төрле яклап сәүдә итү җирлегендә Болгар дәүләтенең культурасы да үскән. Сәүдә итү мөнәсәбәтләренең үсүенә гарәп һәм фарсы халыкларының йогынтысы да көчле булган. 922 елда ислам динен рәсми рәвештә кабул итү – моның төп нәтиҗәсе. Ислам динен кабул итү Идел буе болгарларының Харәзем дәүләте һәм Идел буенда яшәүче халыклар белән элемтәсен тагын да көчәйткән. Бу дәүләтләрдән болгарлар нәфис тукыма, ювелир әйберләр, кыйммәтле кораллар һ.б. зиннәтле әйберләр алып кайтканнар. Боларның барысы да борынгы халкыбызның эстетик зәвыгын булдырырга ярдәм иткән. Тормыш-көнкүрештә гарәп һәм фарсы һөнәрчеләре эшләгән әйберләрне кулланып, болгарлар әкренләп билгеле бер гореф-гадәтләрне, фикерләү рәвешен, дөньяга карашларын формалаштырганнар. Боларның барысы да, алга таба сәүдә мөнәсәбәтләрен киңәйтү өчен, халыкта укырга-язарга өйрәнү омтылышын көчәйткән. Болгарларның культура дәрәҗәсе һөнәрчелек үсеше белән бәйле. Дәүләт барлыкка килгәндә үк һөнәрчелек мөстәкыйль эшчәнлеккә әверелә. Һөнәрчеләр алдан заказ алып та, базарда сату өчен дә әйберләр эшлиләр. Шуңа күрә Болгар дәүләтендә кара һәм төсле металлургия, тимерчелек, пыяла, чүлмәк ясау, тиредән, сөяктән, агачтан әйберләр эшләү, шулай ук ювелир һөнәрчелеге нык үсә бара. Болгар халкына матур әйберләр булдырырга, мул тормышта яшәргә тырышу омтылышы көчле булган. Ул әлеге төбәктә яшәгән халыкларда эстетик зәвык тәрбияләү формалаштыру нигезен тәшкил иткән. Археологик казу эшләре алып барганда фарфор һәм пыяладан, шулай ук кыйммәтле ташлардан (мәсәлән, агаттан) ясалган әйберләр табылган. Табылдыклар арасында алтын һәм көмештән эшләнгән алка, беләзек, балдак, мәрҗән, корычтан эшләнгән кечкенә көзгеләр бар. Хатын-кызлар сердоликтан, тау бәллүреннән, халцедон, яшмадан ясалган мәрҗәннәр асып йөргән.

Пыяладан эшләнгән мәрҗәннәр табылу – пыяла эшләү һөнәрчелегенең нык үсүе турында сөйләүче дәлил. Бронзадан ясалган прәшкәле каешны сугышчылар зур горурлык белән тагып йөрткән.

Болгар гамәли сәнгате өчен хайван, үсемлек рәсемнәре, геометрик фигуралар ясау хас булган. Хайван рәсемнәре ясау стиле мәҗүсилек (күптөрле иләһкә табыну) нигезендә формалашкан. Әмма, XII гасыр ахырында – XIII гасыр башларында ислам дине киң таралгач, сәнгатьтә чынбарлыктагы җанлы нәрсәләрне сурәтләү башка форма, төсмер ала башлый. Үсемлекләрне сурәтләү һәм геометрик орнаментлар ясау киң җәелә бара.

Идел Болгары мәдәнияте үсешенә нәсел шәҗәрәсе төзү билгеле бер өлеш кертә. Татар халкында бу эш кабиләчелек чорыннан ук башлана. Тарихи шәхесләрнең, аларның фамилияләренең туганлык элемтәсен өйрәнүче татар галиме М.И.Әхмәтҗанов әйтүенчә, "туганлык элемтәләре" дигән сүзнең төп мәгънәсен "шәҗәрә" ("нәсел агачы") дигән сүз белдерә. Бу – гарәп термины. Әмма ул шәҗәрә төзүне татарлар гарәпләрдән алган дигән сүз түгел. Әлеге эшне безнең борынгы бабаларыбыз үзләре башлаган һәм ул безнең мәдәни мирасыбыз булып тора.

Хәзерге Татарстан җирлегендә эстетик тәрбиянең асылын аңлауда XVIII, XIX гасырларда барлыкка килгән уку йортларында гади генә итеп алып барылган тәрбия эше зур әһәмияткә ия. Дөрес итеп оештырылган укыту процессы – тәрбиянең, шәхес формалаштыруның мөһим өлеше. Шуңа күрә уку йорты шартларында эстетика, тарих, әдәбиятны, рәсем ясарга, музыка белемен, чит телләрне, сәнгать теориясен өйрәнү тагын да зуррак игътибарга лаек. Яшь кешедә эстетик зәвык тәрбияләүдә укыту фәннәре, тирә-юнь, күрсәтмә әсбаплар, сәхнә спектакльләре, әдәби әсәрләр, әңгәмә, дөрес тормыш итү, кием-салым, бизәнү әйберләре, укытучының киеме, үз-үзен тотышы, сөйләме һ.б. мөһим урын алып тора. Билгеле булганча, укыту процессында сөйләм теле хәлиткеч роль уйный. Шуңа күрә XVIII-XIX гасырларда Казанның кайбер уку йортларында әдәби әңгәмәләр уздырылган, укучыларның трибуна янында торып чыгыш ясавы оештырылган.

XVI гасырда Казан төбәгендә беренче миссионер мәктәпләре барлыкка килә. Аларның оешуы архиепископ Гурий исеме белән бәйле. Ул 1557 елда Казанда үзе нигез салган монастырьлар каршында училищелар ачкан. Аларда православие христианнары белән бергә мөселман мәҗүсиләре балалары да укыган. Бу уку йортларында укырга, язарга, хисапка, дин кануннарын, иске славян телен өйрәткәннәр. Монда төп максат итеп башка милләтләрне руслаштыру куелган.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# "ИЗГЕ ВӘЛИ" КӨНЕ,
## яки гади Фәһрикамал дәгъвасы

***(Ахыры. Башы газетабызның 10, 17 февраль саннарында.)***

Икенче каттагы укытучылар бүлмәсе янында балалар күренми иде. Илгизәрнең сыйныф җитәкчесе Венера ханым әле килеп җитмәгән. Гөлиянең йөрәге дөп-дөп тибә, уенда берсеннән-берсе шомлырак төрле куркыныч күренешләр алышынып тора.

Менә төнлә зур тизлек белән баручы поездның фарасы яктысында кечкенә генә апак куян алга таба чаба. Поезд яктырткычын сүндерми, ә Гөлия-куян рельслардан читкә китә алмый...

Бусы исә кырда үсә торган ялгыз чәчәк. Рәхимсез давыл аны өзеп атарга, юк итәргә маташа, ләкин көчле җилдә җиргә кадәр бөгелә-бөгелә тибрәнгән Гөлия-чәчәк бирешми, сынам дигәндә генә кабат турая, давыл белән бар көченә көрәшә.

Менә ул озын керфекле, горур кыяфәтле матур болан булып урманда чаба. Аны ифрат зур гәүдәле, бик куркыныч юлбарыс эзәрлекли. Хәлдән тайган Гөлия-болан кинәт абынып егыла һәм...

- Әй! Әллә идәнгә кләйләп-ябыштырып куйдыlармы? Нәрсә басып торасыз монда ишек төбендә?

Гөлия сискәнеп куйды. "Куып җитте!" дигән уй аның бөтен тәне буенча салкын дерелдәү булып таралды. Ләкин күкрәкләрне тышка чыгарып җибәрә язган кофта, тәнгә сыланган джинсы чалбар кигән "юлбарысны" күргәч, Гөлия чынбарлыкка кайтып, үзенә кирәк булган укытучыны таныды.

- Исәнмесез, Венера Мәгъсүмовна! Мин Нәбиуллин Илгизәрнең әнисе, бәлки, хәтерлисездер.

- Нигә хәтерләмәскә тиеш ди әле мин сезне? Нәрсә кирәк?

Шулай башланып киткән сөйләшүнең ахыры яхшы булмаячагын абайласа да, Гөлия максатына ирешергә теләп, йомшак, әмма ышанычлы тавыш белән дәвам итте:

- Изге Валентин бәйрәме хакында белешергә килдем мин. Нигә үткәрәсез аны мәктәптә, нәрсәгә кирәк ул?

- Һе, тапкансыз икән үзегезгә баш бәласе. Бүтән кайгыгыз булмаса, тыныч кына өегезгә кайтып китегез!

- Юк, минем беләсем килә. Татарларның үз бәйрәмнәре бар. Нәүрүз, Каз өмәсе кебек чараларны оештырып булмыймыни мәктәптә?

- Ой, не могу! Кемгә кирәк соң ул сезнең каз-үрдәкләр! Йолкыдың-пешердең-ашадың һәм вәссәлам. Ә мәхәббәт ул - мәңгелек нәрсә!

- Алай дисәгез, фәхешлек тә барлык заманнарда булды. Мондый гыйшык-мыйшыкка багышланган чараларда балаларны мәҗбүри катнаштыру - оешкан рәвештә алар арасында иркле мәхәббәтне пропагандалау түгелме соң? Ир-хатын мөнәсәбәтләре ул - бик җитди нәрсә, ә мондый чаралардан яшүсмерләр кирәкмәгән нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

Венера Мәгъсүмовна нечкә иреннәрен кысып, күзләрен тарайтып, башын горур итеп артка таба һәм бераз читкә авыштырып куйды. Аңа каршы булган көндәшнең өстенә запастагы "бомбасын" ташлар алдыннан шулай итә иде ул гадәттә.

- Ирекле мәхәббәт дисеңме? - дип "син"гә күчте юлбарыс. - Ир-хатын мөнәсәбәте җитди нәрсәме? Ә син, ялгыз тавык, нишләп ирең белән тора алмадың соң? Менә хәзер үзең нәтиҗә ясап кара инде, титибаш!

Гөлиянең дөп-дөп типкән йөрәге бөтенләй сикереп чыга язды. Әмма мәдрәсәдә өйрәнелгән әхлак дәресләреннән ул белә иде: бу явызның әшәкелегеннән өстен булырга һәм ничек тә үзеңне кулда тотып калырга кирәк. Хискә бирелеп, аның дәрәҗәсенә төшеп кычкыра башласаң - беттең. Шушы явыз каршында түгел, Аллаһ каршында зур оттыру булыр иде бу. Шуңа күрә, яңакларындагы бер төерен дә селкетмичә, ул лаеклы тынычлыкны саклап "мөгаллимәгә" җавап бирде:

- Ирем Фәнис китүенә мин гаепле түгел. Ул, күрәсең, сезнең кебек укытучыда белем алгандыр: чит кызларга күз салырга шундый Валентин бәйрәмнәрендә бик яхшы өйрәтәсез бит сез. Әнә, мәхәббәт открыткаларын сатуны да шәп итеп оештыргансыз икән. Ләкин белегез: минем улым аны бәрәүгә дә язмады һәм сезнең бүгенге концертыгызда да катнашмаячак!

Шундый көтелмәгән җаваптан соң Венера Мәгъсүмовнаның башы кире нормаль хәленә кайтты, күзләре ачылды, иреннәре исә, ачуыннан дерелди башлады:

- Катнашмыйча гына карасын! МИН анңары аңа көн күрсәтмәячәкмен!

- Шулай инде, - диде тыныч кына Гөлия. - Сезнең кебекләр балаларга көн күрсәтмәс өчен биш ел институтта укыйдыр. Теләсә нишләгез, ләкин Илгизәр хәзер минем белән кайтып китәчәк. Алай гына да түгел, мин аны башка сыйныфка күчерәчәкмен.

Шулай дигәч, Гөлия борылып баскычка таба кузгалып китте. Ачуыннан кабарынган усал укытучы исә артыннан әче тавыш белән кычкырып җибәрде:

- Ычкын моннан, япанча! Беләм мин синең кем икәнеңне! Юньле булсаң, әтәчең ташлап китмәс иде әле, кыткылдык!!!

* * *

...Тынлык. Тып-тын бүлмәдә сәгать текелдәвеннән башка бернинди дә тавыш юк. Инде берничә сәгать диванда кырын яткан Гөлиянең хәленә кереп, бөтен дөнья шау-шулардан туктап, пысып кына аны күзәтә сыман. Фәһрикамал апа да кызының сөйләшмәвенә борчылып, инде ничәнче тапкыр аяк очында гына янына килә дә, аңа дәшә:

- Кызым... Бер генә чынаяк чәй эчеп алмыйсыңмы? Тор инде, гөлкәем, сөйләшик...

Гөлиянең мәктәпкә барганын ул оныгы Илгизәрдән белде. Шуңа да бик сораштырасы килә иде. Нәрсә булды микән соң анда? Әллә килүен ошатмаганнармы?

Бик тыйнак, кече күңелле, йомшак холыклы Гөлия балачактан ук рәнҗетүне йөрәгенә якын ала торган иде. Менә ире дә ничек рәнҗетте бит - бала белән калдырып ташлап китте, хезмәттәшенә өйләнде. Ә ничек ярата иде аны хатыны белән улы!

Шулай да, мәдрәсәгә укырга кергәч, үзгәрде Гөлия. Мәшәкатьле дөньяны, кешеләрнең тупаслыгын тыныч кабул итәргә өйрәнде. Иман- ышанычы айлап, көнләп ныгыды. Әнисенә дә еш киңәш бирә иде ул: "Иң мөһиме - Аллаһ риза булсын; Аллаһ синнән разый булса, кешеләр дә синнән разый булырлар".

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# БОРЫНГЫ БОЛГАРЛАРДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ ЭШЧӘНЛЕК

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

XVIII гасырның икенче яртысыннан башлап рус булмаган халыклар арасында миссионерлык эшчәнлеге (көчләп руслаштыру) көчәя төшә, "яңа керәшен мәктәпләре" ачыла. Аларга рус булмаган милләт (татар, чуваш, мари, мордва, калмык) балалары алына. Әлеге мәктәпләр җирле халык арасында курку тудыра...

Бу чорда берничә төр уку йорты эшли: а) 1732 елда оештырылган духовная семинария (Зилант монастыренда славян-латин монастыре); ә) монастырьларда Гурий оештырган яңа керәшен мәктәпләре; б) солдат балалары укый торган батальон мәктәпләре; в) "чиркәүләрдә һәм тормышта кирәкле фәннәрне" өйрәтә торган "цифир мәктәпләре" (аларга дворян, приказчик, дин әһелләре балаларын кабул иткәннәр).

Казан гимназиясе ачылу мәгариф өлкәсендә яңа бер чорны башлап җибәрә. Императрица Елизавета 1758 елның 21 июлендә аны ачу турында карар кабул итә. Баштарак анда – укырга, язарга, соңыннанрак тарих, география, рус, немец, француз, латин телләрен өйрәтәләр. Гимназия ачылып җиде ай үткәннән соң, укучылар "Странствия телемака"ны тәрҗемә итү белән шөгыльләнгәннәр. Ул Россия уку йортларында йөз елга якын француз теленнән русчага тәрҗемә кылу китабы итеп файдаланылган. Үзенең озак еллар буена яшәү чорында гимназия көнчыгыш телләрен укыту белән аерылып торган: югарыда санап кителгәннәрдән тыш, анда 1770 елдан татар теле, фарсы, төрек-татар теле, монгол, кытай, әрмән телләре, ә 1837-1842 елларда инглиз теле укытылган. Телләр шул телдәге әдәбият белән бергә өйрәтелгән. Бу исә укучыларда эстетик карашлар тәрбияләүгә нык йогынты ясаган.

1804 елда Казанда ачылган университетка буйсынучы уку йортларының уставларын булдыру Россия гимназияләре тормышында зур вакыйга дип санарга кирәк.

1809 ел башында Казан укыту округында биш гимназия булган. Аларда – 315, өяз училищеларында 248 укучы укыган (Россиядә 36 гимназия, 126 училище эшләгән). Рус теленә өйрәтүне көчәйтү максатыннан, 1844 елдан әдәби әңгәмәләр үткәрү кертелгән. Андый чаралар айга ике тапкыр уздырылырга тиеш булган. Укучылар язган иң эчтәлекле сочинениеләр, махсус альбомга теркәлеп, гимназия китапханәсендә сакланган.

Эстетик тәрбия бирүдә 1875 елда ачылган Казан реаль училищесы тәҗрибәсе кызыклы гына. Әлеге уку йортының педагогик совет утырышларында укучылар эшләреннән тупланган коллекцияне һәм рәсемнәрне 1878 елда Парижда оештырылган конкурска җибәрү, сызым яки рәсемне укыту мәсьәләләре хәл ителгән.

1876 елда ачылган Учительская школада да укучыларга эстетик тәрбия бирүгә зур әһәмият бирелә. Анда спектакльләр, әдәби кичәләр үткәрелә, бәйрәм һәм бәйрәм алды көннәрендә бию, уен кичәләре оештырыла, укучылар театрларга һәм концертларга йөри. Әлеге уку йортында рус теле, тарих, география, матур язу, рәсем һ.б. фәннәр укытыла. Мәктәп күрсәтмә әсбапларның күп булуы белән аерылып тора.

Эзләнү-тикшерену нәтиҗәләреннән күренгәнчә, хәзерге Татарстан территориясендә һәм аңа чиктәш төбәкләрдә яшәүче халыкларның балаларында эстетик зәвык тәрбияләүдә сизелерлек эш башкарылган. Ул яшь буынга алга таба белем һәм тәрбия бирү, укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү юнәлеш һәм алымнарын билгеләргә ярдәм иткән. Бу эш шул ягы белән әһәмияткә ия.

***Елена ГАЛИШНИКОВА,***
***педагогика фәннәре докторы, КФУдагы Икътисад һәм финанс институты профессоры***

# Фирдәвес ӘХТӘМОВА якты дөньядан китте



Татарстанның халык артисткасы Фирдәвес Әхтәмованың вафат булуы уңаеннан, республика җәмәгатьчелеге кайгы уртаклаша.

"Татарстан Республикасының театр сәнгате тирән кайгы кичерә. 22 февральдә каты авырудан соң 73 нче яшендә Татарстанның халык артисткасы, милли сәхнәбезнең якты йолдызларыннан берсе Фирдәвес Каюм кызы Әхтәмова вафат булды.

Фирдәвес Әхтәмова - Г.Камал театрында ярты гасыр иҗат иткән күренекле щепкинчыларның берсе иде.

Ф.К.Әхтәмова 1939 елның 21 июлендә Лаеш районының Яушыйк авылында дөньяга килә. Ул әтиләре сугышта һәлак булган буын баласы. Унбер яшьтә әнисез дә калып, абыйсы тәрбиясендә Казанда үсә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, татар театры өчен махсус оештырылган төркем белән Мәскәүгә Щепкин исемендәге югары театр училищесына укырга китә. 1961 елда, аны тәмамлап, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасына кабул ителә.

Кабатланмас талантка, үзенә генә хас аһәңгә, сәхнә гүзәллегенә ия булган артистка, иҗатының беренче адымнарыннан ук, күпсанлы тамашачылар мәхәббәтен яулый. Аның иҗат репертуарында татар, рус, чит ил авторлары әсәрләрендә башкарылган йөзгә якын образ бар.

Төрле елларда башкарылган Фәрхинур - "Гөлҗамал" (Н.Исәнбәт); Мәйсәрә - "Американ", Фатыйма - "Сүнгән йолдызлар", Зөһрә - "Назлы кияү", Шәмси әби - "Казан сөлгесе" (К.Тинчурин); Розалия - "Соңгы хат" (Х.Вахит); Липочка - "Агай-эне ак мыек" (А.Островский); Софья - "Бер төн" (Б.Горбатов); Эльмира - "Дуслар җыелган җирдә", Алтынчәч - "Әниләр һәм бәбиләр", Фирая - "Галиябану, сылуым иркәм" (Т.Миңнуллин); хатын - "Бичура" (М.Гыйләҗев); Фатыйма - "Өчәү юлга чыктык" (Р.Батулла); Җәмилә - "Бәхетсез егет", Биби - "Беренче театр", Бәдигыльҗамал - "Каениш, көндәш һәм башкалар" (Г.Камал); Абруй - "Мәхәббәт турында сөйләшик" (И.Зәйниев) һәм башка рольләре артистканың төрле жанрда да искиткеч тормышчан, табигый һәм хисле уенының үрнәге иде.

Фирдәвес Әхтәмованың иҗаты чын милли халыкчан рух белән сугарылган. Г.Камал әсәре буенча куелган "Беренче театр" телевизион фильмындагы Биби образы Ф.К.Әхтәмова иҗатында һәм, гомумән, татар театры сәнгатендә зур урын алып тора.

2010 елда VI Халыкара "Алтын мөнбәр" мөселман киносы фестивалендә Фирдәвес Әхтәмова, "Бибинур" фильмында төп рольне башкарып, "Иң яхшы хатын-кыз роле" номинациясендә җиңү яулады.

Ф.Әхтәмова хезмәттәшләренә ышанычлы, киң күңелле дус, яшь буын өчен кайгыртучан, ярдәмчел остаз иде.

Халкыбызның сөекле артисткасы Фирдәвес Әхтәмованың якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр", - диелә кайгынамәдә.

P.S.: Фирдәвес апа 22 февраль көнне Әтнә районы зиратында ире янәшәсендә җирләнде. Урыныгыз җәннәттә булсын!

# Кытайда Коръән музее төзеләчәк

Кытайның үзәк өлешенең төньягында (биредә мөселманнар күпләп яши) урнашкан Ганьсу провинциясенең Линься-Хуэйск автоном округы власте Коръән музее төзү өчен дүрт миллион юань (якынча 636000 АКШ доллары) күләмендә акча бүлеп бирергә дигән карарга килгән. Монда изге Коръәннең гарәп телендә язылган иң сирәк һәм борынгы (мең елдан артык "яшәгән" китаплар) экземплярлары сакланачак, дип хәбәр итә www.naseej.net сайты.

Кытай телевидениесеннән рәсми власть вәкиле белдергәнчә, "бүлеп бирелгән акчаларга күргәзмә залларын, видеокүзәтүләрне тәшкил иткән 800 квадрат метрлы музей төзеләчәк, биредә Коръәннең иң борынгы экземплярларын саклау өчен алдынгы технологияләр файдаланылачак". Чиновник шунысын да искәртте: төзелешне быел апрель аенда башлап, аны ел ахырына тәмамлау күздә тотыла.



Шунысын да искәртеп узарга кирәк: Коръәннең Сәмәрканд кәгазеннән (Үзбәкстан) эшләнгән гарәп телендәге 536 битлек борынгы кулъязмасы узган елны Ганьсу провинциясендә табылган иде. Кытай, Бөекбритания һәм Япония белгечләре фикеренә караганда, кулъязмалар IX һәм XI гасыр араларында язылган һәм ул Кытыйда Коръәннең иң борынгы кулъязмасы булып санала.

Борынгы әсәрләрне саклау буенча Кытай милли үзәге әлеге манускриптны кыйммәтле борынгы әсәрләр исемлегенә кертте.

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 25.02.12 | 6:17 | 7:47 | 13:02 | 16:26 | 18:08 | 19:38 |
| *Якшәмбе* | 26.02.12 | 6:14 | 7:44 | 13:02 | 16:27 | 18:10 | 19:40 |
| *Дүшәмбе* | 27.02.12 | 6:12 | 7:42 | 13:02 | 16:29 | 18:12 | 19:42 |
| *Сишәмбе* | 28.02.12 | 6:09 | 7:39 | 13:02 | 16:30 | 18:14 | 19:44 |
| *Чәршәмбе* | 29.02.12 | 6:07 | 7:37 | 13:02 | 16:31 | 18:16 | 19:46 |
| *Пәнҗешәмбе* | 1.03.12 | 6:04 | 7:34 | 13:02 | 16:33 | 18:18 | 19:48 |
| *Җомга* | 2.03.12 | 6:02 | 7:32 | 13:02 | 16:34 | 18:20 | 19:50 |
| *Шимбә* | 3.03.12 | 5:59 | 7:29 | 13:02 | 16:36 | 18:23 | 19:53 |

# "ИЗГЕ ВӘЛИ" КӨНЕ, яки гади Фәһрикамал дәгъвасы

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Юк, Гөлияне авыр сүзләр белән үпкәләтеп булмый хәзер. Рәнҗесә дә, иманына, диненә зыян салсалар гына рәнҗер. Тик кем генә шундый борчуга салды микән аны? Кем? Ә-ә! Шул бәлале Валентиндыр әле моңа сәбәпче! Иртәгә үк мәктәп директорына шалтыратып сөйләшергә кирәк! Иртәгә үк!

Икенче көнне иртүк Фәһрикамал апа мәктәпкә шалтыратты. Шөкер, директор үзендә иде. Аңа бер сүз дә әйтергә ирек куймыйча, карчык кабалана-кабалана бөтен фикер-дәгъваларын әйтеп салды:

- Йөрәгем әрнегәнгә шалтыратам сиңа, җаныкаем! Без, иптәш диpиктыр, татарлар, мөселманнар, ә үзебез күрәләтә югалып барабыз түгелме? Кайлардан таптыгыз ул гомер булмаган "изге Вәли" дигән көннәрне? Борынгыдан килгән изге бәйрәмнәребез рәтенә куя торган көнмени ул? Аннан бит безнең балакайларыбызга бер тамчы да файда юк, ят ул безнең өчен, аңлыйсызмы шуны? Яшьләребез болай да бозылып бара: аларны бит бүген кәмпитер-уеннар, котсыз мәгънәсез кинолар "тәрбияли". Хәзер менә шул кәкре тәрбиягә сез уйлап тапкан Валентиннар да үз өлешен кертә башлаячакмы? Мәхәббәт, гаилә тормышы турында ни дә булса өйрәтәсегез киләме, әнә татарларда никах тәртибе, ир-хатын бурычлары турында сөйләтегез, тыңласыннар балалар. Күңеленә хуш килгәнне барыбер сеңдерәләр алар! Һәм әгәр дә мәгәр уку йортларында безнең гореф-гадәтләребезгә бөтенләй туры килми торган бәйрәмнәрне оештыру дәвам итә икән - белеп торыгыз: гади Фәһрикамал моңа риза түгел! Гади Фәһрикамаллар моңа каршы!

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе директоры***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №8 (125) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-527.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 23 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**